**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2735**
**06.04.2023**

Башкарма комитетның «2020-2022 елларга «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегендә янгын куркынычсызлыгы» муниципаль программасын раслау турында» 2019 елның 21 октябрендәге 5364 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2020-2022 елларга «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегендә янгын куркынычсызлыгы» муниципаль программасын раслау турында» 2019 елның 21 октябрендәге 5364 номерлы карарына (Башкарма комитетның 2020 елның 9 гыйнварындагы 1 номерлы, 2020 елның 30 ноябрендәге 6436 номерлы, 2021 елның 3 мартындагы 1439 номерлы, 2021 елның 1 сентябрендәге 5767 номерлы, 2022 елның 4 мартындагы 1118 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән программаны финанслауны Яр Чаллы шәһәре бюджетында «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгы» 03.10, «Мәктәпкәчә белем бирү» 07.01, «Гомуми белем бирү» 07.02 бүлекләре (бүлекчәләре) буенча каралган акчалар хисабына, 2020 елда – 16 515,89 мең сум; 2021 елда – 17 645,11 мең сум; 2022 елда – 19 941,41 мең сум күләмендә тәэмин итәргә.»;

2) «2020-2022 елларга «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегендә янгын куркынычсызлыгы» программасында:

- 1 бүлектә «Еллар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Еллар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру еллары, мең сум | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2020 | 2021 | 2022 | Тормышка ашыру чорында барлыгы |
| | Муниципаль бюджет | 16 515,89 | 17 645,11 | 19 941,41 | 54 102,41 |
| | Федераль бюджет | - | - | - | - |
| | Республика бюджеты | - | - | - | - |
| | Башка чыганаклар | - | - | | - |
| | Барлыгы | 16 515,89 | 17 645,11 | 19 941,41 | 54 102,41 |

- 3 бүлектә «Программаның максаты, бурычлары, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары һәм чаралар буенча финанслау» таблицасын кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе мөдире Р.К. Шипеевага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2023 елның 6 апрелендәге
2735 номерлы карарына
кушымта

## Программаның максаты, бурычлары, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары һәм чаралар буенча финанслау

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | Финанслау чыганагын күрсәтеп финанслау (мең сум) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел |
| Максат: янгын куркынычсызлыгын һәм гражданнарның сакланышын арттыру, аларның тискәре нәтиҗәләрен кисәтү һәм җиңеләйтү өчен кирәкле шартлар тудыру һәм тәэмин итү | | | | | | | | | | |
| Бурыч: Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чараларны гамәлгә ашыру | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | Муниципаль бюджет | | |
| «Янгын сүндерү-коткару отряды» МБУ материаль-техник тәэмин итү | Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге | 2020-2022 еллар | Алдан билгеләнгән бурычларны үтәүгә әзерлек дәрәҗәсе, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 8464,06 | 9759,93 | 11610,7 |
| Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын үтәү | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2020-2022 еллар | Алдан билгеләнгән бурычларны үтәүгә әзерлек дәрәҗәсе, % | | | 100 | 100 | | 1582,43 | 219,82 |
| Бурыч: шәһәрнең гомуми белем бирү һәм мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү | | | | | | | | | | |
| Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында автоматик янгын | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2020-2022 еллар | Авариясез эксплуатация дәрәҗәсе, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 3354,31 | 2794,64 | 2695,69 |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| сигнализациясенең һәм «Стрелец-мониторинг» программа-аппарат комплексы комплекслы адреслы мониторинг системасының техник әзерлеген тәэмин итү | | | | | | | | | | |
| Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында автоматик янгын сигнализациясенең һәм «Стрелец-мониторинг» программа-аппарат комплексы комплекслы адреслы мониторинг системасының техник әзерлеген тәэмин итү | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2020-2022 еллар | Аварияcез эксплуатация дәрәҗәсе, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 4697,52 | 3508,11 | 5415,20 |
| «Иң яхшы яшь янгын сүндерүчеләр дружинасы» яшь янгын сүндерүчеләр дружиналарының республика смотр-конкурсында катнашу | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2020-2022 еллар | Чаралар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми | | |
| «Гомуми белем бирү оешмаларында укучылар арасында «Куркынычсызлык мәктәбе» республика слёт-ярышында катнашу | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2020-2022 еллар | Чаралар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Укучылар арасында янгынга каршы тематикага иң яхшы инша, иң яхшы рәсем һәм гамәли иҗат өлкәсендә иң яхшы эш конкурсында катнашу | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2020-2022 еллар | Чаралар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми | | |
| барлыгы: | | | | | | | | 16 515,89 | 17 645,11 | 19 941,41 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева